

Россиядә 134 мен авыл бар. Белгечләр кон саен оч авыл юкка чыга, дип чан суга. Халык шәһәргә китү ягын карый. Сонгы сигез ел эчендә генә дә 8,5 мен авыл яшәүдән туктаган. Россия күләмендәге саннар белән чагыштырганда, Мордовиядә хәлләр тотрыклы күренсә дә, уйланырлык, борчылырлык проблемаларыбыз шактый.
Икенче яктан, беттек, юкка чыктык дип яшәсәк, бетәргә дә күп калмый. Авыл кая бара, нинди тенденцияләр күзәтелә, бу хакта гел язып торабыз. Минемчә, авыл үзенә күрә бер дәүләт. Татар авылы гомер-гомергә үзенен эчке тормышы белән яшәгән. 16 гасырда ук татарлар авыл шартларында үзенен дәүләтчелеген сак-лап калган. Икътисад кына түгел, гореф-гадәтләребез дә, рухыбыз да, гомумән, яшәешебез дә авыл аша формалашкан. 20 гасыр башында, янадан дәүләтчелек торгызылганда, авыллар ярдәмгә килүен онытмыйк. Анын үзгәрүенә замана сәбәпче. Ләкин ничек кенә булмасын, татар халкы очен авыл барыбер топ нигез булып кала бирә. Милләтебезнен рухын саклаучы да, үзанын билгеләүче дә ул. Онытмыйк, авылда яшәү шартлары кырыс. Анда эшләп яшәргә кирәк. Тормышны жигелеп тартып алып бармыйсын икән, авылда яшәп булмый. Элек юклык белән тормыш алып барсалар, хәзер барлык белән яшиләр. Мәсәлән, Ельник районындагы кечкенә генә, сүнеп килгән Ликиньё (Шашка) авылында Кәмил Шекур улы белән Гелжихан Рәүф кызы Утешевлар әлегә авылны яшәтеп килүчеләрнен берсе. Бу жирдә аларнын кендек каны тамган, ата-бабалары хезмәт итеп яшәгән. Һәм алар да туган жирләренә тугърылыклы булып калалар; хезмәт итеп матур гына яшиләр. Кәмилнен әтисе – Шекур Мухай улы белән әнисе - Рәбия апа - авылында хормәтле колхозчылар булып иген игкәннәр, бала-чага тәрбияләгәннәр, аларны олы тормыш юлына лаеклы кешеләр булып үстереп . Гелжиханнын да Рәүф әтисе кече Ватанынын хормәтле колхозчысы була, ә әнисе – Рафика апа, укытучы булып эшләгән. Кызына да, педагогик мирасны бүләк итеп, башлангыч сыйныф укытучысы булырга язган.
Кәмил Шекур улы Утешев, Акчеево топ мәктәбен тәмамлап, Краснослободск районы авыл хужалыгы техникумына механниклык профессиясен үзләштерергә дип укырга керә. Унышлы гына тәмамлап, районындагы «Сельхозтехника» олкәсенә профессиясе буенча хезмәткә урнаша. Гомере буе тырышып хезмәт итә.
Гелжихан Рәүф кызы Утешева Ликиньё, Вачеевка (Вачи) авыллары мәктәпләрендә башлангыч сыйныф укучыларын укырга-язарга ойрәтә, белем доньясына алып керә.

Укучылары шунын очен ана рәхмәтлеләр; хормәт итәләр укытучы апаларын. Киләчәккә омет итеп яши Утешевлар; ике малай тәрбияләп үстерәләр, балаларына белем бирәләр. Шәхси хужалыкларында мал-туар асрап, кош-корт, яшелчә үстерәләр. Тан әтәчләре белән торып, тон уртасында гына йокларга ятарга күнеккән инде авыл кешеләре. Шулай тырышмасан, эш бармый ул. Шушы эшләрдән башка авыл тормышын күз алдына да китерә алмыйбыз. Терлек асраудан әллә нинди зур файда килмәсә дә, авылда эш урынын булмаганда очын-очка ялгап барырга, балаларны укытырга житеп бара. Бүген авылда үз-үзенне кайтгыртмасан, үзенә шогыль тапмасан, эш юк дип хокүмәтне сүгеп кенә яшәп булмый бит. Эштән курыкмаган кешегә авылда да менә дигән итеп яшәргә була һәм шулай бетеп барган авылларыбызны, шул исәптән Ликиньё авылын да яшәтүчеләр арасында Утешевларнын роле зур.

Наилә Насырова